КАРАР
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2025 елның 26 октябре № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 N 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хезмәт итәргә чакырылган гражданнарның хатынларыннан, ирләреннән тыш, 2000 сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны:

– Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

– Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору.

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 574 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 298 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 298 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хезмәт итәргә чакырылган гражданнарның хатынларыннан, ирләреннән тыш, 2000 сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны:

– Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

– Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Түбән Уратма авылындагы юлларны ремонтлау).

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Уратма авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Мухаметшин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ *
р 06-685/10
СОВЕТ
НИЖНЕ-
УРАТЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1630003179